ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ СПАССКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ 367 “24” 06 2021 ел

«Татарстан Республикасы Спас муниципаль районында балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру турында» 2020 елның 21 декабрендәге 703 номерлы Спас муниципаль районы башкарма комитеты карары белән расланган 2021 елга Татарстан Республикасы Спас муниципаль районында балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру программасына үзгәрешләр кертү хакында

Баланы яклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру, балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру өчен кирәкле шартлар тудыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Балалар һәм яшьләр ялын оештыру турында» 2020 елның 29 апрелендәге 346 номерлы карары белән Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Программаның 8 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Аз керемле гаиләләрдән һәм авыр хәлдәге гаиләләрдән 182975-00 (Йөз сиксән ике мең тугыз йөз җитмеш биш сум 00 тиен) балаларның ялын, сәламәтләндерүне, мәшгульлекне оештыруга район бюджетыннан» дип язарга.

2. 5 нче таблицаны программага түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Аз керемле гаиләләрдән һәм авыр тормыш хәлендә калган гаиләләрдән булган балалар өчен стационар лагерьда сменалар оештыру»:

| Стацио-нар балалар - сәламәтләндерү лагере исеме | Үткәрү территориясе | Баланс тотучы исеме Балалар сәламәтләндерү лагере | Кеше саны | Көн саны | Туклануның норматив бәясе | Бюджеттан субсидияләр | Ата-аналар түләүе | Башка чаралар (предприятиеләр, җирле бюджет) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| муниципаль бирем нигезендә | | | | | | | | |
| Өстәмә | Спас | Спас | 13 | 18 | 325,00 | | | 76 050,00 |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| белем бирү МБМУ «Болгар» балаларны савыктыру-белем бирү үзәге | муниципаль районының Ржавец поселогы | муниципаль районы башкарма комитеты | 15 | 21 | 325,00 | | | 102 375,00 |
| | | | 2 | 7 | 325,00 | | | 4550,00 |
| | | | | | | | | |

3. Спас муниципаль районының рәсми сайтында http://www.spasskiy.tatarstan.ru һәм хокукый мәгълүматның рәсми сайтында http://www.pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Спас муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Е.В. Савиновка йөкләргә.

Спас муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе В.А.Осокин